ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

26.01.2021 г.Лениногорск № 3

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чаралары турында» 2006 елның 28 декабрендәге 146 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче Татарстан Республикасы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 елның 7 июнендәге 251 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, 2020 елга Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетын үтәү нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казна һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча узган берләштерелгән коллегия Беркетмәсенең 24, 25 номерлы пунктларын, 04.01.2021 елның № ПР-3 үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга

социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 28 декабрендәге 146 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1 пунктта:

«торак өчен түләү чыгымнары,» сүзләреннән соң «җылылык һәм яктырту» сүзләрен өстәргә;

2 абзацта «педагогик хезмәткәрләргә» сүзләреннән соң «мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына (торак мәйданының социаль нормасы чикләрен чикләмичә)» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә тапшыргач бирергә».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорскские вести» газетасында бастырырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Финанс-бюджет палатасы» МУ рәисе Р.Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

Р.Г. Хөсәенов

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72